ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06 сентября 2017г. № 5212

Акчалары күпфатирлы йортлар төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнар реестрына кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Күпфатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Акчалары күпфатирлы йортлар төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнарны зыян күргән гражданнар исәбенә кертү критерийларын һәм зыян күргән гражданнар реестрын алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 2016 елның 12 августындагы 560/пр номерлы Приказы, Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Акчалары күпфатирлы йортлар төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнар реестрына кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге башлыгы Л.М. Кудряшовага әлеге карарны «Челнинские известия» һәм «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны, шулай ук «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге башлыгы Л.М. Кудряшовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2017 елның 6 сентябрендәге
5212 номерлы карарына
кушымта

Акчалары күпфатирлы йортлар төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнар реестрына кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Административ регламент (алга таба – Регламент) акчалары күпфатирлы йортлар төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнар реестрына кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Хезмәттән файдаланучылар: акчалары күпфатирлы йортлар төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган физик затлар (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә (алга таба – Башкарма комитет).

Дәүләт хезмәтен башкаручы – Башкарма комитет карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге (алга таба – Бүлек).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 109 каб.

Бүлекнең урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты,23 йорт, 109 кабинет.

Башкарма комитетның эш графигы:
дүшәмбе – җомга: 8:00 дән 17:00 сәгатькә кадәр,
шимбә, якшәмбе: ял көннәре.
Төшке аш: 12.00 дән 13.00 сәгатькә кадәр.
Белешмә телефоны: 30-56-81, 30-56-80.

Башкарма комитет бинасына керү шәхесне раслаучы документ буенча.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге рәсми сайтының адресы: (http:// www.nabchelny.ru).

1.3.3. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәге юл белән алынырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Башкарма комитет бүлмәләрендә урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә; Татарстан Республикасы дәүләт телләре турында мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) муниципаль хезмәт турындагы мәгълүматларны үз эченә ала;

2) «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайты (http://www.nabchelny.ru) аша;

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru);

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http:// www.gosuslugi.ru);

5) Башкарма комитетта:
телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә – почта аша кәгазьдә, электрон почта mky_ati@mail.ru аша электрон рәвештә.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

«Күпфатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 214 номерлы Федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, №1, ст. 40);

«Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон («Россия Федерациясе законнары җыентыгы», 08.05.2006, №19, ст. 2060);

«Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) («Россия Федерациясе законнары җыентыгы», 02.08.2010, №31, ст.4179);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 12 августындагы 560/пр номерлы Приказы белән расланган зыян күргән гражданнар реестрын алып бару кагыйдәләре (рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 30.12.2016) (алга таба – Кагыйдәләр);

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Законы (алга таба – 45-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы, № 155-156, 03.08.2004);

«Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба - Татарстан Республикасы Законы) ("Татарстан Республикасы", №259, 28.12.2007).

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав);

Башкарма комитет Җитәкчесенең 2008 елның 8 апрелендәге 428 номерлы боерыгы белән расланган Бүлек турында нигезләмә;

Башкарма комитет Җитәкчесенең 2007 елның 6 июлендәге 754 номерлы боерыгы белән расланган эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр);

Башкарма комитетның 2014 елның 11 мартындагы 147-р номерлы боерыгы белән расланган эш регламенты (алга таба- эш регламенты).

1.5. Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның бу мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандарт таләбенең эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең исеме | Акчалары күпфатирлы йортлар төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнар реестрына кертү | |
| 2.2. Турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтә торган башкарма хакимият органының исеме | ТР Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты<br>Дәүләт хезмәтен башкаручы - Башкарма комитет карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге | Бүлек турында нигезләмә |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Башкарма комитетның гариза бирүчене Реестрга кертү турында яисә гариза бирүчене Реестрга кертүдән баш тарту турында карары | Кагыйдәләрнең 8 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы, әгәр туктату Россия Федерациясе законнарында каралган булса | Гариза теркәлгән вакыттан башлап 20 эш көненнән артмаган срокта гариза бирүчене Реестрга кертү турында яисә гариза бирүчене Реестрга кертүдән баш тарту турында карар кабул итү<br>Карар кабул итү өчен кирәкле һәм реестрга кертелергә тиешле мәгълүматларны алу зарурлыгы булган очракта, карар кабул итү срогы 14 эш көненә кадәр озайтылырга мөмкин, бу хакта гариза бирүче адресына 5 эш көне эчендә кабул ителгән карар турында белдерү җибәрелә. | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге | Реестрга кертү өчен гариза бирүче тапшыра:<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:<br>1) шәхесне раслаучы документ күчермәсе;<br>2) зыян күргән граждан һәм торак урынын тапшыру буенча йөкләмәне үтәмәгән проблемалы объектны төзүче арасында хокук мөнәсәбәтләре барлыкка килүне раслый торган өлешләп төзүдә катнашу шартнамәсенең күчермәсе һәм ташлама бирү килешүенең күчермәсе (өлешләп төзүдә катнашучы килешү буенча таләп | РФ Граждан кодексы, 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе гражданнарының Россия Федерациясе чикләрендә күчеп йөрү ирегенә, тору һәм яшәү урынын сайлауга хокукы турында» 1993 елның 25 июнендәге 5242-I номерлы РФ Законы |

| | | |
|---|---|---|
| | хокукына ташлама биргән очракта);<br>3) проблемалы объектка карата төзелгән өлешләп төзүдә катнашу шартнамәсе буенча зыян күргән гражданның бурычларын үтәүне раслаучы түләү документларының күчермәләре (өлешләп төзүдә катнашучы килешү буенча таләп хокукына ташлама биргән очракта);<br>4) зыян күргән гражданның проблемалы объектны төзүчегә карата таләпләрен кредиторларның таләпләре реестрына кертү турында законлы көченә кергән суд актының күчермәсе (булганда) | |
| 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешмалар | Таләп ителми | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда, Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен килештерү (муниципаль хезмәт күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла) таләп ителә торган дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | 1) Башкарма комитет карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге<br>2) Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе<br>3) Башкарма комитетның хокук идарәсе<br>4) Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Документлар тиеш булмаган зат тарафыннан бирелгән.<br>2. Документлар әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләр исемлегенә туры килми;<br>3. Гаризада һәм гаризага теркәлеп бирелә торган документларда килешенмәгән төзәтмәләр, аларның эчтәлеген бертөрле аңлатырга мөмкинлек бирми торган җитди кимчелекләр бар. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен сәбәпләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Гариза бирүчене реестрга кертүдән баш тарту өчен нигез булып тора:<br>1) гариза бирүченең Кагыйдәләрнең 2 пунктында билгеләнгән критерийларның берсенә туры килмәве;<br>2) зыян күргән граждан төзелешендә катнашкан проблемалы объектны файдалануга тапшыру;<br>3) проблемалы объектны төзүченең банкротлыгы турындагы эшне карау кысаларында зыян күргән гражданның таләпләрен канәгатьләндерү (түләү), өлешчә канәгатьләндерү турында суд актының законлы көченә керүе;<br>4) зыян күргән граждан һәм проблемалы объектны төзүче арасында төзелгән өлешләп төзүдә катнашу шартнамәсен өзү (өлешләп төзүдә катнашучы килешү буенча таләпләр хокукына ташлама биргән очракта);<br>5) Кагыйдәләрнең 6 пунктында каралган документларны тулы күләмдә тапшырмау, шулай ук ялган һәм (яки) дөрес булмаган документлар тапшыру. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, мондый түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Чират булганда, дәүләт хезмәтеннән файдалануга гариза бирү – 15 минуттан артык түгел;<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел | |
| 2.13. Гариза бирүченең . Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросын теркәү срогы | Гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә | эш регламенты |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге (бинага уңайлы керү-чыгу, аның чикләрендә хәрәкәтләнү) тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен дә истә тотып урнаштырыла | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 12 пункты |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре | Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>- Башкарма комитет биналарының җәмәгать транспортыннан һәркем файдалана алырлык зонада урнашуы;<br>- кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган бүлмәләр булу;<br>- мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында, ТР дәүләт һәм | |

| | | |
|---|---|---|
| | муниципаль хезмәтләр порталында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>- гариза бирүчеләрдән документлар кабул иткәндә һәм аларга документлар биргәндә чиратлар;<br>- Дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын бозулар;<br>- Дәүләт хезмәте күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаятьләр.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос биргәндә һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда, дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла. Хезмәттәшлек дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында http://www.nabchelny.ru «дәүләт һәм муниципаль контроль» бүлегендә алынырга мөмкин<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба - КФҮ) дәүләт хезмәте күрсәткәндә, консультация бирүне, документларны кабул итү һәм бирүне КФҮ белгече гамәлгә ашыра | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү аша яки Татарстан Республикасының Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша электрон рәвештә алырга мөмкин.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны электрон рәвештә бирү законда каралган булса, ул очракта гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша (http://uslugi.tatar.ru) яки Бердәм | |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы аша http://www.gosuslugi.ru) бирелә. | |

3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультацияләр бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) Реестрга кертү турында карар кабул итү яки сәбәпләрен аңлатып баш тарту;

4) техник хатаны төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы регламентка 2 нче кушымтада тәкъдим ителгән

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү

3.2.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында консультация бирүне сорап КФҮгә шәхсән һәм телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, шул исәптән тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалану өчен башка мәсьәләләр буенча консультацияләр бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм Реестрга кертү башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

3.2.3. Гариза бирүче Башкарма комитетка телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук Республика порталында, Башкарма комитет сайтында муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары, шул исәптән тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалану өчен башка мәсьәләләр буенча консультация алырга хокуклы.

Консультация бирү өчен җаваплы вазыйфаи зат Регламентның 1.3.4 пункты таләпләре нигезендә гариза бирүчегә хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать кергән көннән башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе булып тора: тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалану өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән үзе, ышанычлы зат аша Регламентка 1 нче кушымта нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында язма гариза бирә һәм әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә (алга таба - эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә) документлар тапшыра.

3.3.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризалар кабул итүче белгече гамәлгә ашыра:

гариза бирүченең шәхесен билгеләү;

- гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерү (ышаныч язуы буенча эш иткән очракта);

- әлеге регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булуын тикшерү;

- тапшырылган документларның Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерә (документ күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда бозулар, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм башка алдан килешенмәгән төзәтүләр булмау);

Кимчелекләр булмаган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече башкара:

- электрон документ әйләнеше бердәм ведомствоара системасында гаризалар кабул итү һәм теркәү;

- гаризаны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрү.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризалар кабул итүче белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен

каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гамәлгә ашырыла:

- гариза һәм документлар кабул итү - 15 минут эчендә;

- гаризаны теркәү гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза һәм документлар яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза һәм документларны карап тишерә һәм Башкарма комитет карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге башлыгына (алга таба – бүлек башлыгы) җибәрә.

Процедураның срогы: алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап 1 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: бүлек башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.4. Бүлек башлыгы гаризаны, документларны карый һәм бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бүлек белгеченә җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.5. Бүлек белгече:

1) тапшырылган документлардагы мәгълүматларның дөреслеген тикшерә;

2) әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең булуын тикшерә;

3) гариза бирүченең исәп эшен рәсмиләштерә (барлык документларны аерым папкага туплаый).

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, бүлек белгече гариза бирүчене реестрга кертүдән баш тарту турында белдерү проектын әзерләүне гамәлгә ашыра (алга таба-баш тарту турында белдерү кәгазе) һәм бүлек башлыгына килештерүгә җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, бүлек белгече Башкарма комитетның күпфатирлы йортларны төзү өчен акчалары җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган (алга таба – Башкарма комитет карары проекты) гражданнар реестрына кертү турында карар проектын (алга таба – Башкарма комитет карары проекты) әзерләүне гамәлгә ашыра һәм аны бүлек башлыгына килештерүгә җибәрә.

Процедураның срогы: 1 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: бүлек башлыгына килештерүгә җибәрелгән Башкарма комитет карары проекты яки баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.3.6. Бүлек башлыгы баш тарту турында белдерү проектын карый, килештерә һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә яки Башкарма комитет карары проектын килештерә һәм аны Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә килештерүгә җибәрә.

Процедураның срогы: алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән баш тарту турында белдерү проекты яисә Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә (алга таба-архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе) килештерүгә җибәрелгән килештерелгән карары.

3.3.7. Башкарма комитет Җитәкчесе баш тарту турында белдерү кәгазен имзалый һәм аны бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Башкарма комитет Җитәкчесенә баш тарту турында белдерү кәгазе кергән көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган, бүлеккә җибәрелгән баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.3.8. Бүлек белгече эш кәгазьләрен алып бару идарәсендә баш тарту турында белдерү кәгазен терки һәм аны гаризада күрсәтелгән ысул белән физик затка җибәрә.

Процедураның срогы: гариза бирүчене реестрга кертүдән баш тарту турында белдерү кәгазе теркәлгән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән, гариза бирүчегә җибәрелгән баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.3.9. Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе Башкарма комитет

карары проектын карап тикшерә, килештерә һәм килештерү өчен Башкарма комитетның хокук идарәсенә (алга таба - хокук идарәсе) җибәрә яисә Башкарма комитет карары проектына карата кисәтүләр әзерли һәм аларны бетерү өчен бүлек белгеченә җибәрә.

Процедураларның срогы: Башкарма комитет карары проекты архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә кергән вакыттан башлап 1 эш көне.

Процедураларның нәтиҗәсе: Башкарма комитетның килештерелгән, хокук идарәсенә җибәрелгән карар проекты яисә Башкарма комитет карарына карата бүлек белгеченә җибәрелгән төзәтмәләр.

3.3.10 Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе тарафыннан Башкарма комитет карары проектына карата төзәтмәләр җибәрелгән очракта, бүлек белгече аларны төзәтә һәм килештерү өчен архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә җибәрә.

Процедураның срогы: Башкарма комитет карары проекты төзәтмәләр белән бүлеккә кергән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитетның төзәтелгән, килештерү өчен архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә җибәрелгән проекты.

3.3.11 Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе Башкарма комитетның төзәтелгән проектын карап тикшерә һәм килештерү өчен хокук идарәсенә җибәрә.

Процедураның срогы: Башкарма комитетның төзәтелгән карар проекты Архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә кергән вакыттан башлап 1 эш көне.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитетның хокук идарәсенә җибәрелгән карар проекты.

3.3.12 Хокук идарәсе Башкарма комитетның төзәтелгән карар проектын карап тикшерә, килештерә һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә.

Тапшырылган документлар норматив хокукый актларга туры килмәгән очракта, хокук идарәсе Башкарма комитет карары проектына кисәтүләр әзерли һәм аларны төзәтү өчен бүлек белгеченә җибәрә.

Процедураның срогы: Башкарма комитет карары проекты Хокук идарәсенә кергән көннән башлап 2 эш көне.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитетның килештерелгән, эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты яисә Башкарма комитет карары проектына карата бүлек белгеченә җибәрелгән искәрмәләр.

3.3.13 Башкарма комитет карары проектына хокук идарәсе тарафыннан кисәтүләр җибәрелгән очракта, бүлек белгече кисәтүләрне төзәтә һәм аны алга таба килештерү өчен Хокук идарәсенә җибәрә.

Процедураның срогы: Башкарма комитет карары проекты искәрмәләр белән бүлеккә кергән көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет карарының Хокук идарәсенә килештерүгә җибәрелгән төзәтелгән проекты.

3.3.14 Хокук идарәсе Башкарма комитет карарының төзәтелгән проектын карап тикшерә һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә.

Процедураның срогы: Башкарма комитетның төзәтелгән карар проекты кергән вакыттан башлап 1 эш көне.

Процедураларның нәтиҗәләре: Башкарма комитетның килештерелгән, эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карары.

3.3.15 Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече:

1) Башкарма комитет карары проектын ахыргы вариантта тикшерә;

2) Башкарма комитет вазыйфаи затларының Башкарма комитет проектын җибәрү реестрында кирәкле виза булуын (булмавын) тикшерә

3) Башкарма комитет карары проектын Башкарма комитет бланкында бастыра;

4) Башкарма комитет карары проектын имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Процедураның срогы: Башкарма комитет карары проекты эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә кергән көннән башлап 1 эш көне.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет Җитәкчесенә имзалау өчен җибәрелгән карар проекты.

3.3.16 Башкарма комитет җитәкчесе Башкарма комитет карары проектын имзалый һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә.

Процедураның срогы: Башкарма комитет карары проекты Башкарма комитет Җитәкчесенә кергән көннән башлап 1 эш көне.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты.

3.3.17 Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе гамәлгә ашыра:

1) Башкарма комитет карарының имзаланган проектын карарларны теркәү журналында терки;

2) Башкарма комитет карарының күчермәләрен реестр нигезендә карарлар бирүгә җибәрү.

Процедураның срогы: Башкарма комитет Җитәкчесе карарны имзалаган көнне.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет карарының күчермәләрен реестр нигезендә карарлар бирүгә җибәрү.

Башкарма комитетның теркәлгән, карарлар бирү реестры нигезендә җибәрелгән карары.

3.3.18 Бүлек белгече гариза бирүчене Башкарма комитет карары нигезендә Реестрга кертә

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет карары нигезендә гариза бирүчене реестрга кертү.

Процедураның срогы: Башкарма комитетның гариза бирүчене реестрга кертү турындагы карары эш кәгазьләрен алып бару идарәсендә теркәлгән көнне.

3.3.19 Бүлек белгече гариза бирүчегә аны Башкарма комитет карары белән реестрга кертү турында белдерү җибәрә.

Процедураларның срогы: 3 эш көне.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчене реестрга кертү турында гариза бирүчегә җибәрелгән белдерү кәгазе.

3.4. Техник хаталарны төзәтү.

3.4.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче Башкарма комитетка тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (әлеге Регламентка 4 нче кушымта);

гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы документ;

техник хата булуны раслаучы юридик көчкә ия документлар.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документта күрсәтелгән мәгълүматлардагы техник хатаны төзәтү турында гариза, гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан почта аша (шул исәптән электрон почтадан файдаланып) яисә Республика порталы аша бирелә.

3.4.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итүне гамәлгә ашыра, теркәлгән документлары белән бергә гаризаны терки һәм Башкарма комитет Җитәкчесенә бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедура гариза теркәлгән датадан башлап бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып тора: кабул ителгән, теркәлгән һәм бүлек башлыгына җибәрелгән гариза.

3.4.3. Техник хатаны төзәтү турында гариза килгәндә, дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документка кертү максатларында әлеге Регламентның 3.3.3-3.3.18 пунктларында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Бүлек белгече төзәтелгән документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзасы белән бирә яки гариза бирүчегә почта аша (электрон почта аша) документ алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура җибәрелгән хата турында гариза алганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

### 3.5. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтү

3.5.1. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү өчен КФҮгә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.5.2. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтү КФҮнең билгеләнгән тәртиптә расланган Эш регламенты нигезендә башкарыла.

3.5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен КФҮдән документлар килгәндә, процедуралар әлеге Регламентның 3.3.3-3.3.19 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе КФҮгә җибәрелә.

4. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан Регламент нигезләмәләрен һәм муниципаль хезмәт күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларны үтәүне һәм башкаруны, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы контрольдә тоту тәртибе

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту үз эченә гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә тикшерүләр үткәрү, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карарлар әзерләүне ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документ проектларын тикшерү һәм килештерү;

2) эш башкаруны алып баруга карата билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлеше буенча билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органының ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр үткәргәндә муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле, яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләр кылуга контрольне гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә орган җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар нигезендә билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләре үз вакытында карап тикшерелмәү өчен җаваплы.

Бүлек башлыгы әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең үз вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәлмәве өчен җаваплы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

4.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар ягыннан контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәткәндә җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу аша гамәлгә ашырыла.

5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең, хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар Башкарма комитетның дәүләт хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр тәртиптә Башкарма комитетка шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогын бозу;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге норматив хокукый актларында каралмаган документларны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең башка норматив хокукый актларында каралмаганда, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу.

5.2. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон формада Башкарма комитетка яки Башкарма комитет Җитәкчесенә тапшырыла.

Шикаять «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен кулланып, почта аша, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан http://www.nabchelny.ru Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталыннан http://uslugi.tatar.ru/ дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталыннан http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы - аны теркәгән көннән башлап, унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органга, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи затына шикаять белдерүдән баш тарткан очракта, гариза бирүчедән документларны кабул иткәндә яки җибәрелгән хаталарны һәм хаталарны төзәтүдә яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срокларына карата шикаять белдерелгән очракта-теркәлгән көннән биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүматлар яисә гариза бирүченең – юридик затның урнашу урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре беркетелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять аны биргән дәүләт хезмәтеннән файдаланучы тарафыннан имзалана

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмый, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

Акчалары күпфатирлы йортлар
төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары
бозылган гражданнар реестрына
кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
1 нче кушымта

Акчалары күпфатирлы йортлар төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары
бозылган гражданнар реестрына кертү турында
ГАРИЗА

______________________________________________________________
(җирле үзидарә органының исеме)

Акчалары күпфатирлы йортлар төзү өчен җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган гражданнар реестрына кертүне сорыйм:

______________________________________________________________

Фамилия, исем, атасының исеме (булганда), шәхесне таныклаучы документ мәгълүматлары;

Вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), вәкаләтләрен раслаучы документ мәгълүматлары;

Гариза бирүченең адресы: ______________________________________________

Гариза бирүченең телефоны (факс) ________________________________________

Өлешләп төзү объекты__________________________________
(почта яки төзелеш) адресы,

______________________________________________________________
(торак бинаның номеры, этажлылыгы)

Төзүче оешма: ___________________________________________

Өлешләп төзүдә катнашу шартнамәсенең реквизитлары (өлешләп төзү объектындагы өлешне таләп итү хокукына ташлама ясауның, таләп итү хокукын раслаучы башка шартнамәнең яки документның)________________________________________________

Күпфатирлы йорт төзү максатында акча җәлеп итүне раслаучы түләү документларының реквизитлары _______________________________

Кушымта: ________________________________________________

Гариза бирүче: _____________________________________________

Моның белән «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү йөзеннән, минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм. Шәхси мәгълүматларны эшкәртү дигәндә, шәхси мәгълүматларны җыю, язу, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), алу, файдалану, тапшыру (тарату, бирү, керү), зарарсызлау, блоклау, бетерү, юк итү кебек автоматлаштыру чараларыннан файдаланып яисә файдаланмыйча башкарыла торган теләсә нинди гамәл (операция) яки гамәлләр (операцияләр) җыелмасы күздә тотылуын аңлыйм

Имза_______________________________ "__" _________ 20__ ел
(гариза бирүченең яки вәкилнең Ф.И.А.и.)

Акчалары күпфатирлы йортлар
төзү өчен җәлеп ителгән һәм
хокуклары бозылган гражданнар
реестрына
кертү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына
2 нче кушымта

Блок-схема

Гариза бирүче хезмәт күрсәтү турында гариза бирә һәм Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра

Гариза һәм документлар

Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:
- гариза бирүченең шәхесен ачыклый;
- гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә (ышаныч язуы буенча эш иткән очракта);
- әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булуын тикшерә;
- гариза һәм документларны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә

Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече:
гаризаны электрон документ әйләнеше бердәм ведомствоара системасында кабул итү һәм теркәү, гаризаны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрү.

Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуын хәбәр итә һәм гариза бирүчегә документларны кире кайтара

Гариза бирүчегә җибәрелгән гариза һәм документлар

Кабул ителгән, теркәлгән, Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза һәм документлар

Башкарма комитет Җитәкчесе гариза һәм документларны карап тикшерә һәм Башкарма комитет карамагындагы күчемсез милек объектларың өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге башлыгына

Бүлек башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар

Бүлек башлыгы гариза һәм документларны карап тикшерә һәм

Карап тикшерү өчен бүлек белгеченә җибәрелгән гариза һәм документлар

Бүлек белгече тапшырылган документлардагы мәгълүматларның дөреслеген тикшерүне, әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең булуын тикшерүне, гариза бирүченең исәпкә алу эшен рәсмиләштерүне (барлык документларны аерым папкага туплауны) гамәлгә ашыра.

Бүлек белгече кергән документлар нигезендә гариза бирүчене реестрга кертү турында карар проектын әзерләүне гамәлгә ашыра һәм карар проектын бүлек башлыгына килештерүгә җибәрә

гариза бирүчене реестрга кертү турында бүлек башлыгына килештерүгә җибәрелгән Башкарма комитет карары проекты

Гариза бирүчене реестрга кертүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проекты

Бүлек башлыгы карар проектын карап тикшерә, килештерә һәм АШТһТҮИгә җибәрә

Бүлек башлыгы гариза бирүчене реестрга кертүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын карап тикшерә, килештерә һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә

АШТһТҮИгә җибәрелгән карар проекты

Башкарма комитет Җитәкчесе гариза бирүчене реестрга кертүдән баш тарту турында белдерү кәгазен имзалый һәм аны бүлеккә җибәрә

АШТһТҮИ карар проектын карап тикшерә, килештерә, төзәтмәләр кертә һәм бүлек белгеченә җибәрә

Бүлек белгече карар проектындагы кимчелекләрне төзәтә һәм аны АШТhТҮИгә җибәрә

Бүлек белгече гариза бирүчене реестрга кертүдән баш тарту турында белдерү кәгазен эш кәгазьләрен алып бару идарәсендә терки һәм аны гаризада күрсәтелгән ысул белән гариза бирүчегә җибәрә

гариза бирүчене реестрга кертүдән баш тарту турында имзаланган, гариза бирүчегә җибәрелгән

АШТhТҮ төзәтелгән карар проектын карап тикшерә һәм аны килештерү өчен хокук идарәсенә җибәрә

Килештерелгән, хокук идарәсенә җибәрелгән карар проекты

Хокук идарәсе карар проектын карап тикшерә, килештерә, тапшырылган документлар норматив хокукый актларга туры килмәгән очракта, карар проектына кисәтүләр әзерли һәм Бүлек белгеченә төзәтүгә җибәрә

Бүлек белгече хокук идарәсе кисәтүләрен төзәтә һәм алга таба килештерү өчен хокук идарәсенә җибәрә

Төзәтелгән, хокук идарәсенә җибәрелгән карар проекты

хокук идарәсе Башкарма комитетның төзәтелгән карар проектын карап тикшерә, килештерә һәм аны эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә

Башкарма комитетның төзәтелгән, килештерелгән. эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән карар проекты

Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече:

- Башкарма комитет карары проектын ахыргы вариантта тикшерә;
- Башкарма комитет проектын җибәрү реестрында Башкарма комитет вазыйфаи затларының кирәкле визалары булуын (булмавын) тикшерә;
- Башкарма комитет карары проектын Башкарма комитет бланкында бастыра;
- Башкарма комитет карары проектын имзалау өчен Башкарма комитет Житәкчесенә җибәрә

Имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән карар проекты

Башкарма комитет Җитәкчесенә карар проектын имзалый һәм аны эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә

Имзаланган, эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән Башкарма комитет карары

Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе имзаланган Башкарма комитет карарын теркәү журналында терки, карарның күчермәләрен карарлар бирү реестры нигезендә бирә

Теркәлгән, карарлар бирү реестры нигезендә бирелгән Башкарма комитет карары

Бүлек белгече гариза бирүчене Башкарма комитет карары нигезендә реестрга кертә, аны реестрга кертү турында карарны Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы имзалаган хат белән гариза бирүчегә җибәрә

гариза бирүчене Башкарма комитет карары нигезендә реестрга кертү, гариза бирүчене Башкарма комитет карары нигезендә реестрга кертү турында гариза бирүчегә җибәрелгән карар

Акчалары күпфатирлы йортлар
төзү өчен җәлеп ителгән һәм
хокуклары бозылган
гражданнар реестрына
кертү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына
3 нче кушымта

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ________________________________________________

(хезмәтнең исеме)
Язылган: ______________________________________________
Дөрес мәгълүматлар: ____________________________________
______________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып саналган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:
1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу хакында карар кабул ителгән очракта, андый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

электрон документны E-mail: ____________________ адресына җибәрү юлы белән;

кәгазьдә расланган күчермә рәвешендә почта аша түбәндәге адреска җибәрүне: ______________________________________________________.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), блокировкалауга, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага теркәлгән, минем шәхескә һәм минем тарафтан күрсәтелгән затка кагыла торган, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: _________________.

_______________ ( _________________)  (дата)

__________________ (имза)

Кушымта
(белешмә)

Дәүләт хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның
үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның
реквизитлары

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 30-55-42 | Rinat.Abdullin@tatar.ru |
| Башкарма комитет карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлеге башлыгы | 30-57-65 | goscontrol@list.ru |
| Бүлек белгече | 30-56-80<br>30-56-81 | goscontrol@list.ru |